ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.04.2019 №351

Нурлат муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия житәкчеләре һәм белгечләренең, муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетларының баш хисапчылары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәте өчен түләүне оештыру шартлары турында

Татарстан Республикасы Президенты Р. Н. Миңнехановның боерыгы, Татарстан Республикасы финанс министрлыгының 2019 елның 18 апрелендәге 03-16/2920 хаты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Түбәндәге нигезләмәләрне расларга:

1.1. “Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләренә хезмәт хакын түләү һәм оештыру шартлары турында НИГЕЗЛӘМӘ (1 нче кушымта).

1.2. Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының баш хисапчылары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында НИГЕЗЛӘМӘ (2 нче кушымта).

2. «Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесенә һәм муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләренә «Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе белгечләре, муниципаль берәмлекләрнең (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) башкарма комитетлары баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары вазыйфалары исемнәрен әлеге карарга туры китерүне тәэмин итәргә.

3. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар бүлегенә “Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчесе вазыйфасы исемен әлеге карарга туры китерүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2019 ел, 23 апрель, 351 нче

карары белән расланган 1 нче кушымта

«Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләренә хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында

НИГЕЗЛӘМӘ

1. «Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт хакын оештыру һәм шартлары турында әлеге Нигезләмә(алга таба - нигезләмә) «Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. "Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле елларда эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләүләрдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрләрдән тора.

3. "Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (башка җирле үзидарә органы) структур бүлекчәсе (бүлеге) булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 23 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 21 500 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш хисапчы) | | 21 500 |
| Бүлек башлыгы | 17 700 | 17 700 |

| | | |
|---|---|---|
| Әйдәп баручы бухгалтер | 15 300 | 15 300 |
| Бухгалтер | 14 000 | 14 000 |

Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчесе урынбасары вазыйфасын штат расписаниесенә кертү шарты булып структурада кимендә 5 берәмлек булган штат саны кимендә 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләре штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.

"Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә билгеләнә:

1) түбәндәге күләмнәрдә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процент |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2)вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) еллык түләүле ял биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү елына вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә.

Әгәр хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча декабрьдә эшләнелгән вакытка пропорциональ күләмдә, эштән азат ителгән очракта, эшнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча түләнелә.

Эш елында еллык түләүле отпуск биргәндә хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы елның 31 декабренә эшкә кергән көннән исәпләнә.

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

5) эш нәтиҗәләре буенча ай саен премия:

җитәкчегә вазыйфаи окладның 12% күләмендә,

бүлек җитәкчесе урынбасарларына һәм бүлек башлыкларына вазыйфаи окладның 10% күләмендә,

әйдәп баручы бухгалтерларга (бухгалтерларга) вазыйфаи окладның 7% күләмендә;

зарарлы хезмәт шартлары белән бәйле эшләгән өчен 4% күләмендә (хезмәт шартларын махсус бәяләү булганда).

4. “Муниципаль учреждениеләргә хезмәт күрсәтү үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә еллык хезмәт хакы фонды

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0,3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} Р * (1 + t);$$

монда:

$FOT$ – җитәкчеләр һәм белгечләрнең еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$ – җитәкче һәм белгечнең вазыйфаи окладларын түләү өчен чыганаклар суммасы

$0,3 * O_d$–тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр түләнә торган түләү өчен акча суммасы;

Р – җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык премиаль фонды (әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә торган);

$n$– җитәкчеләр һәм белгечләрнең штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт өчен түләүне хисаплау.

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2019 ел, 23 апрель, 351 нче

карары белән расланган 2 нче кушымта

# Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының баш хисапчылары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында

## НИГЕЗЛӘМӘ

1. Нурлат муниципаль районы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының баш хисапчылары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) (алга таба-бухгалтерларның) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында әлеге Нигезләмә бухгалтерлар эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлый һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәрен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. Бухгалтерларның хезмәт хакы вазыйфаи окладтан, тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, матди ярдәм һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр тәшкил итә.

3. Бухгалтерларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфасы | Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары һәм халык саны | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык |
| Баш бухгалтер | 15 700 сум | 17 000 сум |
| Бухгалтер | - | 14 500 сум |

Муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары штат расписаниесенә бухгалтер вазыйфасын кертү шарты булып муниципаль берәмлекнең халык саны 3,5 меңнән артык кеше исәпләнгәндә кертелә.

3. Бухгалтерларга билгеләнә:

1) түбәндәге күләмнәрдә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процент |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү елына вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә.

Әгәр хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр түләнә торган акча декабрьдә эшләнелгән вакытка пропорциональ күләмдә, эштән азат ителгән очракта, эшнең соңгы көненнән дә соңга калмыйча түләнелә.

Эш елында еллык түләүле отпуск биргәндә хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елында эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт агымдагы елның 31 декабренә эшкә кергән көннән исәпләнә.

4) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә акчалата бүләкләү, матди ярдәм;

5) эш йомгаклары буенча матди бүләкләү – республика әһәмиятендәге бәйрәмнәргә, финанс чыганагы булганда, квартал саен һәм бәйрәмнәргә.

4. Бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT = \sum_{1}^{n}((O_d + 0{,}3 * O_d) * k) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} \mathrm{P} * (1 + t);$$

Монда:

$FOT$ – бухгалтерларның еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$ - бухгалтерга хезмәт хакы түләү өчен акча суммасы;

$0{,}3 * O_d$– тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә бер тапкыр түләнә торган түләү өчен акча суммасы;

Р – бухгалтерларның еллык премиаль фонды (әлеге Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә торган);

$n$- бухгалтерларның штат саны;

$k$ – 12 ай;

$t$ – хезмәт өчен түләүне хисаплау.